КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 15 ноябрь г.Казань № б-2556

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 28 июль, б-1705 нче боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган 2024 елда Казан шәһәрендә «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турниерының волонтерлык программасын гамәлгә ашыру буенча эшче төркем составыннан Н.Д.Пивоварованы чыгарырга;

әлеге боерык белән расланган 2024 елда Казан шәһәрендә «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турнирын оештыручының объектларын һәм шәһәрен комплекслы әзерләү буенча эшче төркем составында:

эшче төркем составыннан А.Г.Пановны чыгарырга;

эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Булатова Эльмира Хәмид кызын | «Казан дәүләт циркы» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе директорын |
| Волчкова Алена Олеговнаны | «СтройИнвестКонсалтинг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «KazanMall» сәүдә-күңел ачу үзәге идарәчесен (килешү буенча) |
| Муллахмәтов Гадел Салават улын | «ЕК-Промоушен» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директорын (килешү буенча) |
| Хәйдәров Марат Рафис улын | «Казан дәүләт аграр университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең «Тулпар» универсаль спорт комплексы директорын (килешү буенча) |
| Шихобалов Валентин Викторовичны | «Татарстан Республикасы Яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директорын; |

әлеге боерык белән расланган 2024 елда Казан шәһәрендә «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турнирының энергетика инфраструктурасын әзерләү буенча эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Габделхаков Рөстәм Рифкать улын | «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте генераль директорын (килешү буенча) |
| Большаков Андрей Викторовичны | «Татарстан Республикасы энергетика системасының төбәк диспетчерлык идарәсе» «Бердәм энергетика системасының система операторы» акционерлык җәмгыяте филиалы директорын (килешү буенча) |
| Галиев Эдуард Геннадьевич | «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Титова Лена Михайловна | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының электроэнергетика бүлеге башлыгын |

әлеге боерык белән расланган 2024 елда Казан шәһәрендә «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турнирының мәдәни, туристлык, тамашачы һәм билет программаларын әзерләү буенча эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Абзалов Азат Искәндәр улын | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгын (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин Эмиль Фидаил улын | «Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы генераль директорын (килешү буенча) |

әлеге боерык белән расланган Видеоуеннар уйлап чыгаручыларның халыкара форумын әзерләү һәм үткәрү буенча эшче төркем составында:

эшче төркем составыннан Р.И.Һидиятуллинны чыгарырга;

эшче төркем составына Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары, эшче төркем җитәкчесе урынбасары Альберт Валерьевич Яковлевны кертергә;

әлеге боерык белән расланган 2024 елда Казан шәһәрендә «Киләчәк уеннары» халыкара мультиспорт турнирын ачу һәм ябу тантанасын әзерләү һәм үткәрү, «Киләчәк шәһәр»не оештыру мәсьәләләре буенча эшче төркем составында:

исемендә «, «Киләчәк шәһәр»не оештыру» сүзләрен төшереп калдырырга;

эшче төркем составыннан А.Н.Лобовны, А.А.Святовны чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин